КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«1» июня 2021 г. № 79-п

Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне
Татарстан Республикасы
массакүләм мәгълүмат чараларында
иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерам:

1. Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс уздыру турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2021елның 1 июненнән
79-п санлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014-2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның оештыручысы – «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Оештыручы, Агентлык);

1.3. Конкурс ел саен, агымдагы елның 30 сентябренә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Конкурсны оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары, гаризалар кабул итәлә башлау һәм төгәлләнү вакыты, аларны бирү тәртибе, бүләкләү күләме, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү вакыты һәм тәртибе күрсәтелә.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар, чәчәкләр һәм акчалата бүләкләр тапшырыла.

1.5. Конкурска бер генә гариза керсә һәм яисә бер гариза да кермәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары игътибарын Татарстан Республикасында халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне, шул исәптән Татарстан

Республикасында яшәүче халыкларның телен, мәдəниятен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуда гаилә кыйммәтләренең ролен яктыртуга җәлеп итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- массакүләм мәгълүмат чараларын мәдәниятләр, халыклар, диннәр үсеше һәм аларның үзара бәйләнеше темасын, мәдәниара һәм динара мөнәсәбәтләрнең һәм хезмәттәшлекнең уңай мисалларын яктыртуга стимуллаштыру;

- журналистларның Татарстан Республикасында халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне яктыртуга багышланган эшләренең дәрәҗәсен арттыру;

- җәмгыятьтә халыклар һәм диннәр арасында татулык һәм килешү культурасы булдыруга ярдәм итү.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

3.1. Конкурста катнашуга гариза тапшыручылар булып, әлеге Нигезләмәнең 5 бүлеге нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәлгән һәм гариза биргән авторлар, авторлык коллективлары яисә редакцияләр тора. (алга таба – гариза тапшыручылар).

3.2. Конкурста катнашучылар булып, конкурс эшләре Конкурста катнашуга тәкъдим ителгән гариза бирүчеләр тора (алга таба – катнашучылар).

3.3. Экспертлар советы – конкурс комиссиясе составына керми торган, Конкурска тапшырылган эшләрне алдан карауны гамәлгә ашыручы, шулай ук конкурс комиссиясенә тәкъдим итү өчен Конкурста катнашучылар рейтингын әзерләүче затлар төркеме.

3.4. Конкурс комиссиясе – Конкурсның экспертлар советы катнашу өчен тәкъдим иткән эшләрне җиңүчеләрне билгеләү максатыннан бәяләүче затлар төркеме.

3.4. Конкурста җиңүче – призлы урын алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар һәм гариза тапшыручылар

4.1. Конкурста Агентлыкның рәсми сайтында күрсәтелгән срокларда гариза һәм эшләр тапшырган авторлар яисә авторлык коллективлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары сыйфатында теркәлгән редакцияләр катнаша.

4.2. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

4.3. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурска моңа кадәр үткәрелгән Конкурс йомгаклары ясалган вакыттан алып чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәмамлану датасына кадәрге чорда массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан эшләр кабул ителә.

5.2. Конкурска түбәндәге документларны кабул итә:

а) конкурс эшләре:

флешкартада MP4 форматында телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы). Конкурс эшләре эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән, ММЧ редакциясе җитәкчесе һәм мөһере куелган эфир белешмәсе белән бергә тапшырыла;

басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә/сканер аша чыгарылган вариантта. Язмалар редакция мөһере (булган очракта) белән һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;

Интернет массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар, алар кәгазь вариантта, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

флешкартада MP3 форматында радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләре эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән, ММЧ редакциясе җитәкчесе һәм мөһере (булган очракта) куелган эфир белешмәсе белән бергә тапшырыла.

б) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча тутырылган анкета конкурс эшләре һәм анкета;

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә иң күбе 10 кеше эшләсә, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

д) физик затлар (авторлар, авторлык коллективлары) өчен:

шәхесне таныклый торган документ (күчермәсе);

шәхси мәгълүматны эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү (тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 2нче кушымтада китерелгән);

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 3нче кушымтада китерелгән);

е) авторлар коллективлары һәм ММЧ редакцияләре өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

Әлеге пунктның «б» – «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта (оешма җитәкчесенең имзасы белән тамгалана һәм оешма мөһере (булган очракта) сугыла) яисә сканердан чыгарып, PDF форматында электрон документ рәвешендә җибәрелә.

5.3. Конкурс эшләре Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясе халыкларының башка телләрендә тапшырыла. Конкурс эшләрен Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясе халыкларының башка телләрендә тапшырган очракта, материаллар җитәкче тарафыннан имза куелган һәм мөһер сугылган (булган очракта) рус теленә тәрҗемә белән тулылана.

5.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

5.5. Анкета-гариза Конкурс үткәрү турында хәбәр белән бергә Агентлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.6. Гаризаларны түбәндәге адрес буенча «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы почта аша яки китереп бирү рәвешендә кабул итә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, 6 кат, 608 нче бүлмә, **«Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс»** дигән тамга белән, тел.: 8 (843) 570-31-12.

5.7. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

5.8. Гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1-5.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында каралган документлар тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау), конкурста катнашуга гариза бирү вакыты бозылу, типография бозымы, шулай ук сурәттә һәм тавышта бозым булган конкурс эшләрен тәкъдим итү Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора.

5.9. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 5 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

5.10. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка чыгымнары һ.б) гариза бирүчеләр/катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.11. Агентлык эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә Конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә.

5.12. Конкурста катнашучылар исемлеге расланганнан соң гаризалар һәм кушымта итеп бирелгән документлар биш эш көне эчендә Агентлык боерыгы белән расланган Экспертлар советына кертелгән экспертларга карау өчен җибәрелә.

5.13. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны Агентлыкның рәсми сайтында өстәмә хәбәр ителә.

## 6. Конкурсның номинацияләре

6.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы медиапроект» (1, 2, 3, 4 урыннар);

«Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктырткан материал» (1, 2, 3, 4 урыннар);

«Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телен, мәдәниятен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуда гаилә кыйммәтләренең ролен иң яхшы яктырткан материал» (1, 2, 3 урыннар).

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

эчтәлекнең Конкурс тематикасын чагылдыруы, аналитика (0-5 балл);

язмаларның, сюжетларның һәм фотоэшләрнең, радиоэшләрнең һөнәрилек дәрәҗәсе (тамашачылар тарафыннан җиңел кабул ителү, сурәтләү чаралары куллану) (0-5 балл);

язмаларның, сюжетларның һәм фотоэшләрнең Татарстан Республикасы халкы өчен тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте булу (0-5 балл);

концепциянең, сценарийның һәм билгеләнгән тематиканы яктыртуның кабатланмаган булуы (0-5 балл).

## 8. **Экспертлар советын һәм конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе**

8.1.Экспертлар советы составы дүрт кешедән төзелә һәм Агентлык боерыгы белән раслана.

8.2.Конкурска тәкъдим ителгән һәрбер эш әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә экспертлар тарафыннан карала.

8.3. Экспертлар советы әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән сайлап алу критерийлары нигезендә эшләрне 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәяли, эшләрнең һәрбер номинация буенча аерым рейтингын формалаштыра һәм Комиссиягә бәяләмә тапшыра.

8.4. Экспертлар комиссиясе катнашучылар рейтингын Конкурсны оештыручы гаризаларны тапшырган көннән алып 10 эш көне эчендә әзерләп тапшыра.

8.5.Экспертлар советы бәяләмәсе нигезендә конкурс комиссиясе Конкурсның җиңүчеләрен билгели.

8.6. Конкурс комиссиясе составы алты кешедән төзелә, Агентлык боерыгы белән раслана һәм комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм әгъзаларыннан тора.

8.7. Конкурс комиссиясенең эше утырышта башкарыла. Утырыш, әгәр анда әгъзаларның ким яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

8.8. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә торган урынбасарга йөкләнә.

8.9.Конкурс комиссиясе, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокта, Экспертлар советы бәяләмәсе нигезендә җиңүчеләрне билгели. Гариза бирелгән номинациядә иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип танылa.

8.10. Номинацияләрнең берсенә бер генә гариза бирелсә яки бер гариза да бирелмәсә, йә бер генә гариза да конкурс шартларына туры килмәсә, шулай ук номинациядә җиңүче билгеләнмәгән очракта, әлеге номинациядә конкурс үтмәгән дип танылa һәм акчалар башка номинацияләрдә билгеләнгән җиңүчеләргә тигез өлешләрдә бүленә.

8.11. Баллар саны тигез булганда, номинациядә призлы урын конкурс комиссиясе тарафыннан ике яки берничә катнашучыга бирелә. Бу очракта тиешле призлы урын өчен каралган акчалар Конкурсны оештыручы тарафыннан җиңүчеләр арасында тигез өлешләрдә бүленә.

8.12. Берничә ММЧ редакцияләре тарафыннан тәкъдим ителгән конкурс эше җиңсә, әлеге номинациягә билгеләнгән акчалар алар арасында ирешелгән килешү нигезендә бүленә, ул әлеге документлар пакеты белән бергә тапшырыла.

8.13. Оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документларны алып бару өчен жюри җаваплы секретарь билгели.

8.15. Җаваплы секретарь түбәндәгеләрне башкара:

материалларны конкурс комиссиясе тарафыннан карауга әзерли һәм аларның сакланышын тәэмин итә;

конкурс комиссиясе әгъзалары белән элемтәдә тора;

конкурс комиссиясе утырышларын әзерли;

конкурс комиссиясе беркетмәләрен рәсмиләштерә;

8.16. Җаваплы секретарь экспертлар советы һәм конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

8.17. Җаваплы секретарь Экспертлар советы утырышы йомгаклары буенча конкурс эшләренең рейтингын рәсмиләштерә, ул эчендә утырышта катнашкан экспертлар тарафыннан биш эш көне имзалана.

8.18. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

## 9. Финанс белән тәэмин итү

9.1. Конкурсны үткәрү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан билгеләнгән финанс елына бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән финанслана.

9.2. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә (сумнарда):

| № | Номинацияләр | Урын | Сумма |
|---|---|---|---|
| 1 | «Массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы медиапроект» | 1 урын | 60,0 |
| | | 2 урын | 50,0 |
| | | 3 урын | 40,0 |
| | | 4 урын | 30,0 |
| 2 | «Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне иң яхшы яктырткан медиапроект» | 1 урын | 60,0 |
| | | 2 урын | 50,0 |
| | | 3 урын | 40,0 |
| | | 4 урын | 30,0 |
| 3 | «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телен, мәдәниятен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуда гаилә кыйммәтләренең ролен иң яхшы яктырткан материал» | 1 урын | 60,0 |
| | | 2 урын | 50,0 |
| | | 3 урын | 40,0 |

9.3. Премияләр, җиңүчеләр игълан ителгәннән соң, беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында аларның исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә, исәп-хисап счеты Конкурсны оештыручыга җибәрелгән хатта күрсәтелә.

9.4. Физик затларга акча беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында беркетмә нигезендә аларның банк счетына күчерү юлы белән түләнә (исәп-хисап счеты Конкурсны оештыручыга җибәрелгән хатта күрсәтелә) яисә Агентлыкның финанс бүлегендә кулларына тапшырыла.

## 10. Аерым шартлар

10.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;

эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

10.2. Конкурсның шартлары үзгәрү турында хәбәр ителгәннән соң Конкурста катнашучы эшләрне элеккеге шартларда кабул итүне яки Конкурс үткәрү шартларына кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Конкурста катнашу эшне яңа шартларга яраклаштырып төзәткәннән соң гына мөмкин була.

Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне**
**Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурста катнашу өчен**
**АНКЕТА-ГАРИЗА**

**Автор (яисә иҗат коллективы):**_______________________________________________

**Номинация исеме:**_______________________________________________

**Эшнең исеме:**
_______________________________________________

**Кыскача аннотация:**
_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

**Телефон/факс:**
_______________________________________________

**Электрон адрес:**
_______________________________________________

**Адрес:**
_______________________________________________

(ФИ Ат. ис*, имза)
Гариза «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан түбәндәге адрес буенча почта аша яки китереп бирү рәвешендә белән кабул ителә: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2, 6 кат, 608 нче бүлмә.
Тел/факс: (843)570-31-12
*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(тәкъдим ителгән форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,______________________________________________________________,
яшәү адресым_______________________________________________
_________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
_______________________________________________________________
_________________________________________, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.
Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

__________________________________________________________/__________
(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. һәм имзасы)

______________
(Дата)

Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә
3 нче кушымта
(тәкъдим ителгән форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)
______________________________________________________________________,
(почта адресы)
______________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)
______________________________________________________________________,
(телефон номеры)
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10[1] статьясы нигезендә «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» гомумроссия фотоконкурсын оештыручы «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Адрес | | |
| | Белем | | |
| | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| **1. [**Персональ белешмәләрнең категориясе**]** | | |
| | **[**Персональ белешмәләрнең исемлеге**]** | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

______________( персональ белешмәләр субъекты имзасы)

______________ (число, ай, ел)